Республика Татарстан
Новоимянское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге

РЕШЕНИЕ
22.11.2024ел

КАРАР
№13

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл жирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 1 абзацы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 08.08.2024 N 232-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман муниципаль районының «Яңа Имән авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Яңа Имән авыл жирлеге Советы нигезендә карар иттем:

1. Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл жирлегенең 2022 елның 14 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл жирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Жирле үзидарә органы житәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында жирле үзидарә органы житәкчесе урынбасары әлеге органның сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен алар тарафыннан тиешле вазыйфаны биләү чорында тапшыра алмый.»;

2) 9.3 пунктның 5 пунктчасында «һәм квалификация турында»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Имән авыл жирлеге
Советы рәисе Р.Ф.Гараев